



# Мастер класс (осталык дәресе) “Татар теле дәресләрендә синквейн технологиясен куллану”

*Тел – белемнең ачкычы, акылның баскычы.*

***Халык мәкале***


*Укытучы:Бадретдинова Резида Баязитовна*


2016 ел



# Нәрсә соң ул синквейн?

**Синквейн** – иҗади фикерләүне үстерүче методик алым,француз сүзе, «биш илһам», «биш уңыш» дигәнне аңлата. Ул рифмалашмаган бишьюллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр. Билгеле план буенча языла, предметны (төшенчәне) ачыклый.



# Синквейн язу тәртибе

## Синквейн 5 юлдан тора


1 сүз

2 сүз

3 сүз

4 сүз

1 сүз





# Үткәрү максаты

- Сөйләм телен үстерә.
- Эчтәлек сөйләүгә әзерли.
- Идеяне билгеләргә өйрәтә.
- Укучы үзен шагыйрь итеп хис итә.
- Барлык балалар да яза ала.





# Синквейн алымнары

- Дәрес башында: «Бу тема буенча мин нәрсә беләм?»
- Дәрес уртасында: «Тема үзләштерү ничек бара?»
- Дәрес азагында: «Нинди максатларга ирештек?»





# Синквейн язу тәртибе

**1 юл** — **1 сүз**. Темаы ачыклаучы сүз, исем. (Кем? Нәрсә?)

**2 юл** — **2 сүз.** Теманы сурәтли торган 2 сыйфат (Нинди?)

**3 юл** — **3 сүз.** Темага хас булган 3 фигыль. (Нишли?)

**4 юл** — **4 сүз.** Темага карата үз мөнәсәбәтеңне белде-рүче фраза, җөмлә (афоризм, мәкаль, цитата)

**5 юл** — **1 сүз.** Темага карата 1 синоним сүз (нәтиҗә, ассоциация).





# Нәрсә турында синквейн язарга була?

- **Темасы төрле булырга мөмкин:**

❖ *табигать;*
❖ *әдәби герой, персонаж;*
❖ *әни, әти һәм башка гаилә әгъзалары;*
❖ *күңел халәте;*
❖ *дәрестә өйрәнгән тема;*
❖ *…*



# Укучылар

***Көз***

***Сары, яңгырлы.***


***Коела, ява, салкыная.***

***Агачлардан алтын яфраклар коела.***

***Матурлык.***

***Минзалиева Алия4нче сыйныф***

# Укучылар



Кыш

Салкын, карлы.

Туңдыра, шатландыра, бүләк итә.

Кыш бабай бүләкләр алып килә.

Яңа ел.

Галиуллина Рәзинә, 2 нче сыйныф.

# Укучылар

***Казан***

***Матур, чиста,***

***Үсә, яхшыра, яши.***

***Мин Казан шәһәрен бик яратам***


***Ватан.***

***Кудамасов Владислав, 7 нче сыйныф.***





# Укучылар иҗаты




Каюм Насыйри
Белемле, күпкырлы
Укыткан, белгән, өйрәнгән
Мин К. Насыйридан үрнәк алам
Галим.


Мугаллямова Илнара, 4 нче сыйныфы








1.
2.
3.
4.
5.



# Татар теле

…И туган тел,
и матур тел…




# Синквейнның нәтиҗәлелеге

Синквейн алымы иҗади сәләтләрне үстерүгә, дөрес бәяләүгә, үзаллы карар кабул итүгә өйрәтә.Зур күләмле информацияне гомумиләштерүгә, катлаулы мәсьәләләрне гадиләштерергә булышлык итә. Синквейнны язуның төгәл тәртибе укучының фикерен дөрес формалаштырырга, төп фикерне билгеләргә ярдәм итә. Мондый иҗади эш башкару – җиңел, күңелле, файдалы. Сөйләм теле камилләшә, авыр төшенчәләр үзләштерелә.Синквейн төзү укучыдан уку материалында иң мөһим элементларны табуны, йомгаклау ясауны һәм шуны берничә сүз белән ( кыска итеп) әйтеп бирүне таләп итә.Синквейн алымы ярдәмендә дәреснең төрле этабында укучыларның ассоциацияләре белән танышырга мөмкин.



# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!